
Әхмәтгалиева, А. Сабак / А. Әхмәтгалиева // Көмеш кыңгырау. – 2025. – №25 (28 июнь). – Б. 3.



**Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА,**
*язучы, драматург, журналист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*

# Сабак

Балачакка үрелеп карагач, уземә мин алай бер дә тәртипсез куренмим күренүен. Истәлекләрне барлый башлагач, төрле хәлләр калкып чыга.

Бер әйберне әйтим әле. Мин ирек чикләүне ниндидер кысага мәҗбүриләп кертүне һич яратмыйм. (Хәер, кем яратсын инде...) Мөгаен, бу хис балачакта ук булгандыр. Исемдә, бәләкәйрәк чак, әле укырга кермәгән идем, өйдә берүземне калдырдылар. Әни ишекне тыштан бикләде дә мәктәпкә кереп китте. Иптәшкә бераздан Гөлнур апа килеп җитәсе икән, янәсе, ул ачып керер... «Бикләмә», дигәнемне генә хәтерлим, әйткәнмендер инде, беркая чыкмыйм, курыкмыйм, дигәнмендер... Сүземне сүз итәсе килү булганмы ул, протест белдерүме, ишегалдына чыгып йөгерергә теләүме - анысын белмим. Кыскасы, тәрәзәне ваттым мин. Идәндә торган озынча җиз тасны алдым да тәрәзәәә чәпәдем... Бакча ягында да, эчтә дә пыяла ватыклары, төрле рәвешкә кереп, матур булып тырпаеп калган очлы пыяла сөңгеләре күз алдында. Ул арада Гөлнур апа да килеп җитте, ишекне тыштан «аккурат» кына ачып, «аккурат» кына өйгә керде...

*Авыл йортындагы веранданы күз алдына китерегез әле. Буйдан-буйга тәрәзә. Юк-юк, барысын да ватмадым инде. Идәндә торган озынча җиз тасны алдым да бер тәрәзәтасны алдым да бер тәрәзәгә генә чәпәдем. Челтерттттччч... Шул тавыш кына истә.*

Аннан соң ниләр булганын сөйләмим. Ченки... хәтерләмим. Авыл жирендә ничек, каян пыяла юнәткәннәрдер - анысын да белмим... Әйткәнемчә, бүген дә дүрт стена арасында бикләнеп утыруны җенем сөйми, чиксезлек эзләп тик йөрим.

Тормыш сабагы булган тагын бер вакыйга искә төште менә. Мин йөзә белми идем, чөнки күрше кызы Илсөяр белән аларның бакча артындагы инешкә кәлүштер-итектер юарга төшсәк тә, анда су тездән генә, чупырдап кына кайтабыз. Ә теге оч кызлары Айман буасына йөриләр, беркөнне Рәмзия, Гөлназ, Энҗегә ияреп, мин дә шунда киттем. Кызлар ярга басалар да, шуннан суга сикерәләр, аннан колач салып йөзеп китәләр. Соң җайлы гына кебек инде: башкалар йөзә алгач, мин дә йөзәрмен шикелле. Тоттым да нәкъ шулай итеп сикердем һәм... бултыйййх... Кызлар үзләре хәтерли микән, мине кайсы сөйрәп чыгарган - һич искә төшерә алмыйм. Тик шуннан соң ничек тә өйрәнергә дип максат куйдым бит әй. Айман буасына аяк басу юк югын, Илсөяр белән икәүләп Сылу апалар очындагы буага юл тоттык. Имеш,ул мине иплэп кенә өйрәтәчәк... Барып житсәк, андаааа...безнең урамның бөтен малай-шалае кайнаша. Килгән хутка берсе кулдан эләктереп тә алды, суга алып кереп тә китте



. Әнекәем! Су тездән... билдән... муеннан... Куркудан чыр-чыр килгәнмендер инде, малайларга ни, ишшу да кызык табып көлгәннәрдер, анысы артык хәтердә дә калмаган. Ә менә буа уртасына җиткәч, шунда чак күренеп торган «агачка» чытырдап ябышуым бик истә. (Агач булмаган инде ул, батып калган ат арбасы икән). Торам шулай үземә диңгез кебек тоелган (хәзер генә шулай дим, ул чакта каян андый уй килсен, диңгез кургән бармыни әле) су уртасында, йөзә белмәгәнемне күреп торалар - коткарырга җыенучы куренми. Шундый чакта үз-үзекә ышану көче туа да икән ул: миңа ничек тә моннан чыгарга кирәк, миңа ничек тә йөзәргә өйрәнергә кирәк, миңа ничек тә сынатмаска кирәк, миңа ничек тә батып калмаска кирәк... Башкаларның ничегрәк селтәнгәнен карап-карап тордым да тәвәккәлләлләдем. Һәм... ярга йөзеп чыктым!

Шул көндәге сабак әлегәчә онытылмый: димәк, кешенең максаты һәм ышанычы, тырышлыгы булса, теләсә кайсы авырлыкны рәхәтләнеп жиңәргә мөмкин